Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе
«82 нче «Көнбагышкай» катнаш балалар бакчасы»

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ЯШӘҮЧЕ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ТУГАН ТЕЛЛӘРЕН САКЛАП КАЛУГА ҺӘМ ҮСТЕРҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЕКТЫ:

## *«Татар телендә сөйләшәм, эшлим, тәрбиялим»*

Яр Чаллы шәһәре, 2022

**Аңлатма.**

**Кереш өлеш.** Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждение «82 нче «Көнбагышкай» катнаш төрдәге балалар бакчасы» 1979 елдан бирле эшли. 1989 елдан башлап татар балалар бакчасы статусына ия.

Балалар бакчасында мәктәпкәчә яшьтәге балаларда татар телендә бәйләнешле сөйләм һәм рухи-әхлакый сыйфатлар булдыру коллектив эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше булып тора.

Балалар бакчасында 12 төркем эшли. Аларга 275 бала йөри. Тәрбия-белем бирү процессы татар телендә башкарыла.

Белем бирү процессының сыйфатын тәэмин итү максатында, татар телен белүче 100% кадрлар белән комплектланган. Балалар бакчасында 31 педагог эшли, шуларның 29 ы югары белемле, 80% педагог беренче һәм югары квалификацион категорияле.

Татарстан Республикасында дәүләт телләре булып татар һәм рус телләре кабул ителгән. Димәк, Республикабызда һәр баланың туганнан алып ике телдә дә сөйләшергә өйрәнү мөмкинлеге бар. Яшерен түгел, статистика күрсәтүе буенча, бигрәк тә, шәһәр җирлегендә яшәп тәрбияләнгән балаларның ана телен (бу очракта, татар телен) белү дәрәҗәсе төрлечә. Сәбәп, әти-әниләрнең балалары белән ике телне катнаштырып аралашуында. Күп очракта, әти-әниләр балаларына туган телләрендә мөрәҗәгать итә башлыйлар, аннан җөмләне, әйтик, рус телендә тәмамлыйлар. Яки инде киресенчә. («Улым, син садикта бүген что кушал?»). Нәтиҗәдә, бала катнаш сөйләм ишетә һәм аны аралашу нормасы итеп кабул итә. Әйе, балаларның бер телдән икенче телгә аңлап күчү сәләтләре югары. Ләкин катнаш сөйләм аларда буталчыклык барлыкка китерә.

Яр Чаллы шәһәренең 82 нче «Көнбагышкай» балалар бакчасы барлык 12 төркемендә дә белем һәм тәрбия бирү тулысынча татар телендә алып барылуы белән аерылып тора. Шуңа күрә дә, без балаларның татар телендә дә, рус телендә дә дөрес аралашуына аеруча игътибар итәбез. Бу проблеманы чишү юлы буларак, татар төркемендә эшләүче тәрбиячеләр өчен икенче кечкенәләр төркеменнән алып мәктәпкә әзерлек төркеменә кадәр дөрес татар телендә «Тәрбия һәм белем бирү буенча көндәлек эш планы» төзү өстендә эш башладым. Бу эш 2020 нче елның

сентябрь аенда башланды. Бу башлангыч мине «Татар телендә сөйләшәм, эшлим, тәрбиялим» проектын төзүгә китерде.

**Проект чишә торган проблема.** Көн кадагында торган проблемаларның берсен - татар телендә методик әсбапларның бик аз булуын, педагогларның сайлап алу мөмкинлеге булмауны ничек чишәргә соң?

**Проектның актуальлеге.** Шәһәр балалар бакчаларында укыту-тәрбия эшләре төп нигездә рус телендә алып барыла. Билгеле, һәр балалар бакчасында да татар төркемнәре бар, әмма, методик әсбапларның күбесенчә рус телендә булуы татар төркемендә эшләүче тәрбиячеләр өчен кыенлыклар тудыра. Тәрбиячеләрнең сайлап алу мөмкинлеге булмау сәбәпле, рус телендәге әсбаплардан шөгыль конспектларын, планнарын тәрҗемә итү эшләре белән өстәмә утырырга туры килә. Ә бу исә күп вакыт, эзләнүләр таләп итә. Нәтиҗәдә, дөрес булмаган тәрҗемәләр барлыкка килә.

**Проектның яңалыгы**. Белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәр өчен көндәлек эш планнары булдыру ул - тәрбиячеләргә таянып эшләү өчен җирлек булдырып, аларга сайлап алу мөмкинлеге тудыруда.

**Проектның практик әһәмияте.** Проект бүгенге көндә бик мөһим, чөнки хәзерге шартларда республика күләмендә дә балалар бакчаларының татар төркемнәрендә тәрбиячеләр өчен таянып эшләр өчен татар телендә бердәм көндәлек планнарга ихтыяҗ күптән барлыкка килгән иде.

***Бу белем бирү проекты булып тора***, чөнки мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар телендә тулы кыйммәтле белем алырга мөмкинлек бирә. Ата-аналарның процесста катнашуы мәҗбүри дип санала. Алар проект кысаларында үткәрелә торган чараларда актив катнашалар.

***Бу проект инновацион,*** уникаль, заманча белем бирү технологияләрен гамәлгә кертүгә юнәлтелгән: триквейн, мультифест, кейслар чишү һәм башкалар, алар туган телдә белем бирү һәм тәрбия бирү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерүгә ярдәм итә.

***Проектны гамәлгә ашыру*** коллективтан шәхси сыйфатларның булуын таләп итә: җаваплылык, түземлелек, ситуациядә тиз ориентлашу, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның кызыксындыру сәләтенең үстерә белү, проблемаларны стандарт булмаганча хәл итү һәм тәрбияләнүчеләргә индивидуаль якын килү.

**Проектның максаты:**

Татар телен популярлаштыру, ФДББСна һәм төп белем бирү программасына таянып белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәр өчен 3 яшьтән башлап 7 яшькә кадәрле балалар өчен көндәлек эш планнары төзү һәм опробация үткәрү.

**Проектның бурычлары:**

- Тәрбияче хезмәтенең оешканлыгын тәэмин итү.
- Тәрбиячегә программа материалын бер елга тигез итеп бүлү.
- Материалны кирәгенчә генә үтәргә мөмкинлек бирү, төрле алым һәм ысулларны алдан уйлау.
-Тәрбияче бүген нәрсә үтәргә кирәклеген, нинди әсбаплар һәм атрибутлар кирәк булачагын белә ала.
- Балаларда көндәлек тормышта туган сөйләмне куллану теләген үстерү.
-Туган телгә мәхәббәт, үз-үзеңне хөрмәт итү, татар милли мәдәниятенә, республикада яшәүче халыклар мәдәниятенә хөрмәт хисе формалаштыру.
- Бер уку елы эчендә планнар нигезендә опробация үткәрү.

***Белем бирү өлкәләре интеграциясе:*** «Социаль аралашу үсеш», «Танып-белү үсеш», «Сөйләм үсеш», «Нәфис-нәфасәти үсеш», «Физик үсеш».

***Кадрлар белән тәэмин ителеш:*** мөдир, өлкән тәрбияче, балаларны туган теленә өйрәтүче тәрбияче, психолог, логопед, физик тәрбия буенча инструктор, музыка җитәкчесе, тәрбиячеләр.

***Проектта катнашучылар:*** балалар бакчасы педагоглары, тәрбияләнүчеләр, социаль партнерлар, Яр Чаллы педагогика көллияте, Чаллы дәүләт педагогия университеты.

***Проектны гамәлгә ашыручы аудитория:*** 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар - 275 бала.

**Методик тәэмин ителеш.** Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы, балалар бакчасының төп белем бирү программасы, Р.К. Шәеховның «Төбәк мәктәпкәчә белем бирү»; Ф.Хазратова, З.Шәрәфетдинова, И.Хәбибуллина укыту-методик комплекты «Туган телдә сөйләшәбез», З.М.Зарипова, Р.С. Исаева укыту-методик комплекты «Говорим по-татарски» (өлешчә); С.Әхмәтов «Уйныз да, җырлыйбыз да»; С.В. Закиров «Балачак

- уйнап үсәр»; М.Ф. Кашапова «Иң татлы тел-туган тел», М.Ф. Кашапова «Уйныйк әле балалар», Р.Ягфаров «Татар балалар фольклоры», «Татар халык уеннары», «Ал кирәк, гөл кирәк», «Алтын кашык», Е.В.Колесникова «Математика для детей», Л.И.Пензулаева «Физкультурные занятия в детском саду», авторлык методик әсбаплары.

***Техник чаралар:*** проектор, интерактив такта, компьютер, магнитофон, микрофон.

«Татар телендә сөйләшәм, эшлим, тәрбиялим» проекты - мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре тәрбиячеләре, өстәмә белем бирү учреждениеләре педагоглары өчен гамәлгә ашыруга билгеләнгән.

***Гамәлгә ашыру срогы*** - озак сроклы, 2 елга билгеләнгән (+ 1 ел эш тәҗрибәсен уртаклашу өчен бирелә).

**Проект гамәлгә этаплап ашырыла.**

**I этап -** оештыру-әзерлек этабы. Бу чорда проект темасының актуальлеге, максаты, бурычлары билгеләнә. Төрле программалар өйрәнеп, методик ярдәмлекләр өйрәнеп барлык проектта катнашучылар белән алып барылырга тиешле эшнең перспектив планын төзелә.

**II этап –** белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәр өчен көндәлек эш планнарын төзү.

**III этап** – белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәр өчен көндәлек эш планнарын опрабоцияләү һәм гамәлгә ашыру.

**VI этап –** эш нәтиҗәләрен гомумиләштерү, эшчәнлеккә анализ ясау, проектның эш нәтиҗәләре белән педагогларның канәгатьлелеген билгеләү, булган нәтиҗәләрне фаразлана торган нәтиҗәләр белән чагыштыру этабы.

**V этап –** эш тәҗрибәсен шәһәр, регион күләмендә уртаклашу.

Проектны гамәлгә ашыруда күпкырлы **эш формалары** кулланыла: тәҗрибә уртаклашу буенча стажировка һәм база мәйданчыкларында, педагогик сәгатьләрдә мастер-класслар, тематик шөгыльләр, әңгәмәләр, дидактик уеннар, сюжетлы рольле уеннар; әти-әниләр белән эшне, балалар белән мөстәкыйль эшчәнлекне күрсәтү, белем өлкәләрендә тәрбиче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге, режим моментлары, авторлык матур әдәбият әсәрләре һ.б.

**«Минем педагогик лаборатория».**

**I этап (сентябрь 2020 - октябрь 2020) - оештыру-әзерлек этабында** проект темасының актуальлеге, максаты, бурычлары билгеләгәннән соң программалар, методик ярдәмлекләр өйрәнеп барлык проектта катнашучылар белән алып барылырга тиешле эшнең перспектив планын төзедем.

Төп программалардан тыш, сүзлек запасын баету, балаларның бәйләнешле сөйләмен формалаштыру, татар телендә режим моментларында файдалану өчен авторлык программалары һәм методик ярдәмлекләр өйрәнелде: Г.Г. Халимова, Г.Р.Миндиярова, Г.Г.Тухбатуллина «П, Пь, Б, Бь авазлары. 5-7 яшьлек балаларда авазларны ныгыту һәм дифференциацияләү буенча уеннар һәм сөйләм материалы»; Г.Г. Халимова, Г.Р.Миндиярова, Г.Г.Тухбатуллина «Л, Ль, Р, Рь авазлары. 4-7 яшьлек балаларда авазларны ныгыту һәм дифференциацияләү буенча уеннар һәм сөйләм материалы»; Р.С.Исаева «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм үсеше»/база мәйданчыгының эш тәҗрибәсе материаллары; Л.Р.Султанова «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда уен эшчәнлеге аша сөйләм үстерү».

Балалар бакчасы педагоглары эшләгән методик ярдәмлекләр, авторлык программалары һәрьяклап физик, социаль-шәхес, танып белү-сөйләм, сәнгати-эстетик үсешкә юнәлтелгән һәм балалар үсешен милли мәдәният чыганакларына, туган якны өйрәнүгә, татар теленә берләштерү юлы белән баетуны күздә тота.

Планны язганда, мәгълүмати технологияләрне гамәлгә кертү максатыннан, интерактив тактада һәм проекцион техникада башкару өчен үстерешле уеннарны һәм биремнәрне өйрәндем. Балалар бакчасында интерактив такталар, проекторлар, ноутбуклар, мультимедиа программалары, заманча техник җиһазлар (ламинатор, төсле принтер, брошюратор, музыка үзәге һ.б.) бар. Әлеге җиһаз татар телендә дидактик һәм интерактив уеннар булдыру өчен педагоглар тарафыннан файдаланылды: Р.С.Исаева «200 игр»; А.Ф.Мухаметова, Л.Р.Сабирова «Минем беренче уеным»; А.Ф.Мухаметова, Л.Р.Сабирова «Төсләр иленә сәяхәт»; Г.Г.Халимова, Г.Г.Тухбатуллина «Рәсемле сүзле уеннар»; Г.А.Халитова, Л.А.Исмагулова «Рәсемле уеннар»; Л.М.Хайруллина «Күңелле поезд»; Г.Г.Тухбатуллина «Звуковая божья коровка».

Яр Чаллы дәүләт педагогия институты, Яр Чаллы педагогия көллияте учреждениеләре ярдәмендә методик әсбаплар өйрәнелде. Стажировка рамкасында

педагоглар белән белем бирү өлкәләре («Социаль аралашу үсеш», «Танып-белү үсеш», «Сөйләм үсеш», «Нәфис-нәфасәти үсеш», «Физик үсеш») буенча түгәрәк өстәл, квест формаларында эшләдем.

**II этап (ноябрь 2020-август 2021) – белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәр өчен көндәлек эш планнарын төзү этабы.**

Бу этапны башлаганчы бакчабыз тәрбиячеләре арасында анкеталаштыру үткәрдем. Анкета нәтиҗәсе, чынлап та, мондый планнарның булуы әһәмиятлелеген тагын да ассызыклады.

Планлаштыру - тәрбиячегә программа материалын бер елга тигез итеп бүлергә, үз вакытында ныгытырга, материалны кирәгенчә генә үтәргә мөмкинлек бирә, төрле алым һәм ысулларны алдан уйларга ярдәм итә. План булу нәтиҗәсендә тәрбияче бүген нәрсә үтәргә кирәклеген, нинди әсбаплар һәм атрибутлар кирәк булачагын белә ала. Дөрес төзелгән план тәрбиячenең эшен җиңәләйтә, эшенә ачыклык кертә, вакытын экономияли, җаваплылыгына арттыра.

Шәһәр күләмендә генә түгел, гомумән, республика күләмендә белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәренә таянып эшләр өчен татарча көндәлек эш планнары үрнәге булмау проблемасы булуы исбатланды. Көндәлек планнарны дүрт яшь аралыгы, ягъни, 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр, 4-5 яшьлек - уртанчылар, 5-6 яшьлек - зурлар, 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән эшләү өчен төзергә карар кылынды.

Көндәлек план: режим, белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлегенә, балаларның мөстәкыйль эшчәнлегенә, ата-аналар белән эш бүлекләреннән тора.

Көнлек режим СанПиН кагыйдәләрен исәпкә алып эшләнелде:

1. ***Иртәнге, көндезге, кичке саф һавада йөрүне планлаштыру.*** Балаларга 3 тапкыр, тиешле вакыт аралыгында саф һавада йөрү билгеләнде. Саф һавада йөрү иртә-кич: күзәтүдән башлана, аз хәрәкәтле уен планлаштырыла. Табигатьтә кыска күзәтәләр һәм җәмгыяти тормыш күренешләре керә. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алып, темалар катлаулаулана: ел вакытлары, йорт һәм кыргый хайваннар, туган шәһәр тормышы һ.б. Көндезге саф һавада йөрүгә бу эш төрләреннән тыш хәрәкәтле уен да кертелә. Планда уеннарның максатлары күрсәтелә. Тәрбиячenең белән балалар эшчәнлеген иртән, саф һавада булганда, кич

белән планлаштыра. Нәкъ менә әлеге эшчәнлекләр барышында тәрбияче балаларны алдагы материалны үзләштерүгә әзерли, күзаллауны, аңлау сәләтен ныгыта, тирәнәйтә, ачыклау өстендә эшли.

***2. Иртәнге вакытны планлаштыру.*** Бу өлкә үз чиратында, төркем/төркемчәдә эш, шәхси эш, режим моментларына бүленә. *Төркем/төркемчәләрдә* эш иртәнге гимнастикадан башлана, сүзле уеннар, “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплектыннан уеннар, уен ситуацияләре, дидактик уеннар, җырлы-биюле уеннар планлаштырыла. Һәр эшчәнлеккә максат билгеләнә.

*Шәхси эштә* авазлар өстендә, баланың үзләштерү мөмкинлекләрен исәпкә алып, төрле уеннар аша үткән материалны ныгыту, кабатлау эше каралган. Шулай ук максатлар билгеләнә.

*Иртәнге режим моментында* бер төркем балалар белән, аерым бала белән, балалар теләге буенча килеп туган яки алдан билгеләнгән темаларга кыска әңгәмәләр планлаштырыла. Иртәнге кабул итү-тәрбиячenең һәр бала белән шәхсән аралашуы өчен иң кулай вакыт. Иртә-тыныч режим моменты. Бу вакытта педагогик балаларны бакча тормышының гомуми ритмына кертеп җибәрү, аларда күңел күтәренкелеге барлыкка китерә.

***3. Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге:*** иҗтимагый файдалы хезмәттән, төзелеш уеннарыннан тора.

***4. ББЭ-белем бирү эшчәнлеге.*** Бу өлештә шөгыль челтәре буенча тиешле эшчәнлек урнаштырыла. Үткәрелә торган шөгыльләрнең характерын да исәпкә алырга кирәк. Акыл активлыгы таләп ителә торган шөгыльләрдә зур хәрәкәтле уеннар оештырыла. Ә физкультура яки музыка шөгыльләре булса, киресенчә аз хәрәкәтле тыныч уеннар карала.

***5. Йокы алды эшчәнлеге.*** Дежур тору күнекмәләрен ныгытыла. КГК (культура гигиеник таләпләр): ашагач, авызларны чайкауны күнектерү, киемнәрен дөрес итеп төреп куярга гадәтләндерү. Йокыдан соң гимнастика үткәрү зарури.

***6. Кич.*** Көндезге йокыдан соң хезмәт эшчәнлеген оештыру отышлы: төркем бүлмәсен җыештыру; китаплар, әсбаплар, өстәл уеннарын ясау, яңарту; курчак киемнәрен юу; бәләкәйләр, уеннар өчен кулдан уенчыклар ясау. Көннең икенче яртысына планлаштыру баланың алдагы эшчәнлегенә таяна: күзәтүләр, уеннар,

хезмәт, физик күнегүләр, хәрәкәтле уеннар. Ләкин кич белән баларның нерв системасын ярсытулы зур  хәрәкәтле уеннар үткәрелми. Бу вакыт өлешен балаларның уен эшчәнлеге алып тора.

*7.* ***Ата-аналар белән эш*** формасы буларак, әңгәмә билгеләнә. Теманы режим моментлары буенча да, тәрбияви максатлардан чыгып та оештырырга була. Әңгәмә шәхси яки барлык әти-әниләр белән дә булырга мөмкин.

**Көндәлек план эчтәлегендә:** махсус оештырылган бәйрәм чаралары, театрлар вакыты билгеләнә. Көндәлек эш планында физик эшчәнлек, интеллектуаль, куркынычсызлык чаралары буенча эш төрләренең дөрес бүленеше булырга тиеш. Тар белгечләрнең тәкъдимнәрен исәпкә алына. Логопед төркемнәрендә мәсәлән, кабатлау эшләре, яки татар теле белгече, музыкант һ.б.тар белгечләр үзләренең тәкъдимнәрен тәрбиячегә бирәләр.

Планны бер үк төркемдә эшләүче ике тәрбияченең дә бергә төзүе мәҗбүри шарт булып тора.  Болай эшләү балаларны бертөрле якын килү, аларга бертөрле таләпләр кую һәр тәрбиячене план һәм программа төзү өчен җаваплылыгын арттыра.

Искәртеп үтәм, бу якынча эш планы. Чөнки көндәлек эш планы төзегәндә һәр тәрбияче бу эшне иҗади якын килеп үз бакчасының спецификасын (эш юнәлешләрен), аның төп белем бирү программасын, максатларын искә алып башкара. Шуңа күрә, бу кулланманы нигез итеп алып, үзгәрешләр кертеп, үзегезгә яраклаштырып кулланырга була.

**III этап (сентябрь 2021-май 2022) – белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәр өчен көндәлек эш планнарын опрабоцияләү һәм гамәлгә ашыру.**

Сентябрь аеннан 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр (№5, №12), 4-5 яшьлек – уртанчылар (№7, №8), 5-6 яшьлек – зурлар (№3, №9, №11), 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек  (№2, №4, №6, №10) төркеме балалары белән шушы көндәлек планнар нигезендә эш башланды. Эш барышында стажировка кысаларында регион һәм шәһәр педагогларына мастер-класслар, ачык шөгыльләр күрсәтелде. Педсоветта план эчтәлеге буенча квест уен, интеллектуаль уен, түгәрәк өстәл сөйләшүләре булган хаталарны төзәтергә булышты.

**VI этап (июнь 2022) – эш нәтиҗәләрен гомумиләштерү.**

Эшчәнлеккә анализ ясау өчен апрель аенда тәрбиячеләр арасында йомгаклау анкетасы үткәрелде. Бу проектның эш нәтиҗәләре белән педагогларның канәгатьлелеген билгеләргә ярдәм итте. Дөрес төзелгән план тәрбияченең эшен җиңәләйткән, вакытын экономияләгән, планнарны иҗади якын килеп төзергә мөмкинлек күбәйгән. Рус телендәге әсбаплардан шөгыль конспектларын, планнарын тәрҗемә итеп өстәмә утыруның кирәге калмаган. Балаларга татар телендә белем һәм тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеге артты. Анкета нигезендә алынган нәтиҗәләр фаразлана торган нәтиҗәләр белән тәңгәл килде.

**V этап (сентябрь 2022-май 2023) – эш тәҗрибәсен шәһәр, регион күләмендә уртаклашу.**

**Көндәлек план төзүнең перспектив планы.**

| № | Тема һәм эчтәлеге | Эш формасы | Вакыты | Катнашучылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 1. | Проблеманы өйрәнү | Минем педагогик лаборатория | сентябрь 2020 | Солтанова Л.Р., НГПУ, педагогик көллият педагоглары |
| 2. | Педагоглар белән беренчел анкета үткәрү | Анкета | сентябрь 2020 | Солтанова Л.Р., төркем тәрбиячеләре |
| 3. | Балалар бакчасы программаларын, авторлык метолик әсбапларны өйрәнү | Минем педагогик лаборатория | сентябрь 2020 | Солтанова Л.Р. |
| 4. | Көндәлек план төзегәндә таяныр өчен методик әсбаплар | Түгәрәк өстәл | сентябрь 2020 | мөдир, Солтанова Л.Р., Яр Чаллы дәүләт педагогия институты мөгаллимнәре, тәрбиячеләр |
| 5. | Белем бирү өлкәләре буенча эшне оештыру | Методик ринг | сентябрь 2020 | мөдир, Солтанова Л.Р., Яр Чаллы педагогия көллияте мөгаллимнәре, тәрбиячеләр |
| 6. | «Фикерләр кәрзине» | Квест уен | сентябрь 2020 | мөдир, Солтанова Л.Р., төркем тәрбиячеләре |
| 7. | Мастер-класс: “Режим моментларын оештыру” | Стажировка мәйданы | октябрь 2020 | мөдир, Солтанова Л.Р., төркем тәрбиячеләре |
| 8. | Белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла торган төркемнәр өчен көндәлек эш планнарын | Проект эшчәнлеге | ноябрь 2020 | Солтанова Л.Р. |
| 9. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр өчен көндәлек план төзү бүлекләре: | Минем педагогик | декабрь 2020 | Солтанова Л.Р. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | - режим;<br>- белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге;<br>- балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге;<br>- ата-аналар белән эш | лаборатория | | |
| 10. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр өчен белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге төрләре:<br>- төркем/төркемчәдә эш;<br>- шәхси эш;<br>- режим моментлары | Минем педагогик лаборатория | декабрь 2020 | Солтанова Л.Р. |
| 11. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр өчен режим бүленеше:<br>-иртәнге саф һавада йөрүне планлаштыру;<br>-көндезге саф һавада йөрүне планлаштыру;<br>-кичке саф һавада йөрүне планлаштыру | Минем педагогик лаборатория | декабрь 2020 | Солтанова Л.Р. |
| 12. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр өчен режим бүленеше: ББЭ-белем бирү эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | декабрь 2020 | Солтанова Л.Р. |
| 13. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр өчен режим бүленеше: йокы алды эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | гыйнвар 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 14. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр өчен режим бүленеше: кичке вакытны планлаштыру | Минем педагогик лаборатория | гыйнвар 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 15. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр өчен мөстәкыйль эшчәнлекләрне билгеләү | Минем педагогик лаборатория | гыйнвар 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 16. | 3-4 яшьлек – икенче кечкенәләр төркеме балаларының ата-аналары белән эш | Минем педагогик лаборатория | гыйнвар 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 17. | 4-5 яшьлек – уртанчылар өчен көндәлек план төзү бүлекләре:<br>- режим;<br>- белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге;<br>- балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге;<br>- ата-аналар белән эш | Минем педагогик лаборатория | февраль 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 18. | 4-5 яшьлек – уртанчылар өчен белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге төрләре:<br>- төркем/төркемчәдә эш;<br>- шәхси эш;<br>- режим моментлары | Минем педагогик лаборатория | февраль 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 19. | 4-5 яшьлек – уртанчылар өчен режим бүленеше:<br>-иртәнге саф һавада йөрүне планлаштыру;<br>-көндезге саф һавада йөрүне планлаштыру; | Минем педагогик лаборатория | февраль 2021 | Солтанова Л.Р. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | -кичке саф һавада йөрүне планлаштыру | | | |
| 20. | 4-5 яшьлек – уртанчылар өчен режим бүленеше: ББЭ-белем бирү эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | февраль 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 21. | 4-5 яшьлек – уртанчылар өчен режим бүленеше: йокы алды эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | март 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 22. | 4-5 яшьлек – уртанчылар өчен режим бүленеше: кичке вакытны планлаштыру | Минем педагогик лаборатория | март 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 23. | 4-5 яшьлек – уртанчылар өчен мөстәкыйль эшчәнлекләрне билгеләү | Минем педагогик лаборатория | март 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 24. | 4-5 яшьлек – уртанчылар төркеме балаларының ата-аналары белән эш | Минем педагогик лаборатория | март 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 25.<br>. | 5-6 яшьлек – зурлар өчен көндәлек план төзү бүлекләре:<br>- режим;<br>- белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге;<br>- балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге;<br>- ата-аналар белән эш | Минем педагогик лаборатория | апрель 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 26. | 5-6 яшьлек – зурлар өчен белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге төрләре:<br>- төркем/төркемчәдә эш;<br>- шәхси эш;<br>- режим моментлары | Минем педагогик лаборатория | апрель 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 27. | 5-6 яшьлек – зурлар өчен режим бүленеше:<br>-иртәнге саф һавада йөрүне планлаштыру;<br>-көндезге саф һавада йөрүне планлаштыру;<br>-кичке саф һавада йөрүне планлаштыру | Минем педагогик лаборатория | апрель 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 28. | 5-6 яшьлек – зурлар өчен режим бүленеше: ББЭ-белем бирү эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | апрель 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 29. | 5-6 яшьлек – зурлар өчен режим бүленеше: йокы алды эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | май 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 30. | 5-6 яшьлек – зурлар өчен режим бүленеше: кичке вакытны планлаштыру | Минем педагогик лаборатория | май 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 31. | 5-6 яшьлек – зурлар өчен мөстәкыйль эшчәнлекләрне билгеләү | Минем педагогик лаборатория | май 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 32. | 5-6 яшьлек – зурлар төркеме балаларының ата-аналары белән эш | Минем педагогик лаборатория | май 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 33. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек өчен көндәлек план төзү бүлекләре: | Минем педагогик | июнь 2021 | Солтанова Л.Р. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | - режим;<br>- белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге;<br>- балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге;<br>- ата-аналар белән эш | лаборатория | | |
| 34. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек өчен белем бирү өлкәләрендә тәрбияче һәм балаларның бердәм эшчәнлеге төрләре:<br>- төркем/төркемчәдә эш;<br>- шәхси эш;<br>- режим моментлары | Минем педагогик лаборатория | июнь 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 35. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек өчен режим бүленеше:<br>-иртәнге саф һавада йөрүне планлаштыру;<br>-көндезге саф һавада йөрүне планлаштыру;<br>-кичке саф һавада йөрүне планлаштыру | Минем педагогик лаборатория | июнь 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 36. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек өчен режим бүленеше: ББЭ-белем бирү эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | июнь 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 37. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек өчен режим бүленеше: йокы алды эшчәнлеге | Минем педагогик лаборатория | июль 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 38. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек өчен режим бүленеше: кичке вакытны планлаштыру | Минем педагогик лаборатория | июль 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 39. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек өчен мөстәкыйль эшчәнлекләрне билгеләү | Минем педагогик лаборатория | июль 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 40. | 6-7 яшьлек – мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының ата-аналары белән эш | Минем педагогик лаборатория | август 2021 | Солтанова Л.Р. |
| 41. | №5, №12 нче икенче кечкенәләр төркемнәрендә көндәлек планнарга опробация үткәрү | Опробация | сентябрь 2021 апрель 2022 | Балалар бакчасы тәрбияләнүчеләре, Галимова Р.Г., Шакирова Л.З., Ахметова А.М., Кадырова Л.Р. |
| 42. | №7, №8 нче уртанчылар төркемнәрендә көндәлек планнарга опробация үткәрү | Опробация | сентябрь 2021 апрель 2022 | Балалар бакчасы тәрбияләнүчеләре, Хайруллина Л.М., Фатыхова Э.Д., Валеева А.И. |
| 43. | №3, №9, №11 нче зурлар төркемнәрендә көндәлек планнарга опробация үткәрү | Опробация | сентябрь 2021 апрель 2022 | Балалар бакчасы тәрбияләнүчеләре, Муллагалиева А.А., Исмагулова Л.А., Галиуллина Р.И., Алексеева Р.М., Пакреева Л.М. |
| 44. | №2, №4, №6, №10 нчы мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә көндәлек | Опробация | сентябрь 2021 | Балалар бакчасы тәрбияләнүчеләре, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | планнарга опробация үткәрү | | апрель 2022 | Сагдеева А.А., Рахматуллина А.Р., Халитова Г.А., Загидуллина Р.Р., Солтанова Л.Р., Хайруллина Л.М. |
| 45. | Педагоглар белән йомгаклау анкетасы үткәрү | Анкета | май 2022 | Султанова Л.Р., тәрбиячеләр |
| 46. | Эш тәҗрибәсен публикацияләү | Публикация | май 2022 | Мөдир Исаева Р. С, Солтанова Л.Р. |
| 47. | Эш тәҗрибәсе белән шәһәр, регион күләмендә уртаклашу. | Сайтка элү | сентябрь 2022 май 2023 | Мөдир Исаева Р.С., Солтанова Л.Р. |

**Фаразлана торган нәтиҗәләр.**

**Педагоглар өчен:**

- Татар телен популярлаштыру.

- Татар телендә көндәлек план булдыру, рус телендәге әсбаплардан тәрҗемә итү эшләре белән өстәмә утырмаулары.

- Тәрбиячеләргә таянып эшләү өчен җирлек барлыкка килә, аларның сайлап алу мөмкинлеге булу.

- Тәрбияче хезмәтенең оешканлыгын тәэмин итү.

- Материалны кирәгенчә генә үтәргә мөмкинлек бирү, төрле алым һәм ысулларны алдан уйлау.

- Тәрбияченең бүген нәрсә үтәргә кирәклеген, нинди әсбаплар һәм атрибутлар кирәк булачагын белә алуы.

**Балалар өчен:**

- Балаларның татар телендә белем һәм тәрбия алуын тагын да кызыклырак итеп оештыру.

- Балаларда көндәлек тормышта туган сөйләмне куллану теләген үстерү.

-Туган телгә мәхәббәт, үз-үзеңне хөрмәт итү, татар милли мәдәниятенә, республикада яшәүче халыклар мәдәниятенә хөрмәт хисе формалаштыру.

**Проектны гамәлгә кертү бәяләре.**

Контроль эксперимент барышында бирелгән күрсәткечләргә бәя бирү индивидуаль һәм фронталь тикшеренүләр һәм әңгәмәләр рәвешендә уздырыла.

**Белемнәрне һәм күнекмәләрне ачыклау методы.**

Көндәлек план нигезендә балалар белем дәрәҗәсен билгеләү контроль эксперимент барышында гамәлгә ашырыла, индивидуаль һәм фронталь

тикшеренүләр һәм әңгәмәләр рәвешендә уздырыла. Уен алымнары һәм күп санлы күрсәтмә предметлы әсбаплар, нәфис әдәбият кулланыла.


Түбәндә тәкъдим ителә торган таблицаларда ФДББС таянып көндәлек план нигезендә үткәрү өчен диагностика инструментарийлары бирелә.

**Көндәлек планнар буенча 3-7 яшькә кадәрле балаларның белем бирү дәрәҗәләрен үзләштерү карталары җыелмасы.**

**Якынча белем дәрәҗәләрен билгеләү (балл)**

| **Дәрәҗә** | **Йомгаклау күрсәткечләре (балл)** |
|---|---|
| Югары | 2,6-3 |
| Уртача | 1,6-2,5 |
| Түбән | 1-1,5 |

**Көндәлек планнар буенча балаларның белем бирү үзләштерү дәрәҗәсе**.




2021-2022 елда – яңа төзелгән планнар буенча күрсәткеч.

**_Кулланылган әдәбият._**

Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы –Казан, 2016.

Балалар бакчасының төп белем бирү программасы – 2021.

Р.К. Шәеховның «Төбәк мәктәпкәчә белем бирү»- Казан, 2014.

Ф.Хазратова, З.Шәрәфетдинова, И.Хәбибуллина укыту-методик комплекты «Туган телдә сөйләшәбез» -Казан, 2013.

З.М.Зарипова, Р.С. Исаева укыту-методик комплекты «Татарча сөйләшәбез» (өлешчә)- Казан, 2013.

С.Әхмәтов «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да». – Яр Чаллы, 1991.

С.М. Гаффарова «Изучаем русский язык». – Казань, 2013.

К.В. Закирова «Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак» - Казан, 2012.

К.В. Закирова «Балачак аланы». – Казань, 2011.

К.В.Закирова, Р.Г.Борһанова «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы». – Казань, 2000.

М.Ф. Кашапова «Иң татлы тел-туган тел». - Казан, 2004.

М.Ф. Кашапова «Уйныйк әле балалар». - Казан, 2011.

Е.В.Колесникова «Математика для детей». - Москва, 2013.

Л.И.Пензулаева «Физкультурные занятия в детском саду».- Москва, 2011.

Р. Ягфаров «Татар балалар фольклоры». - Казан, 2011.

Р.Ягъфәров «Ал кирәк, гөл кирәк».– Казан, 1995.

Р.Ягъфәров «Алтын кашык». – Казан, 1996.

Р.Ягъфәров «Кәҗә-мәкәрҗә». - Казан, 1994.

Ф.Ю. Юсупов «Гөлбакча». - Казань, 1990.

*Авторлык методик әсбаплары:*

Г.Г. Халимова, Г.Р. Миндиярова, Г.Г. Тухбатуллина «П, Пь, Б, Бь авазлары. 5-7 яшьлек балаларда авазларны ныгыту һәм дифференциацияләү буенча уеннар һәм сөйләм материалы»- Яр Чаллы, 2020.

Г.Г. Халимова, Г.Р. Миндиярова, Г.Г. Тухбатуллина «Л, Ль, Р, Рь авазлары. 4-7 яшьлек балаларда авазларны ныгыту һәм дифференциацияләү буенча уеннар һәм сөйләм материалы» - Яр Чаллы, 2020.

Р.С.Исаева «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм үсеше»/база мәйданчыгының эш тәҗрибәсе материаллары, Яр Чаллы, 2019.
Л.Р.Султанова «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда уен эшчәнлеге аша сөйләм үстерү», Яр Чаллы-2016.
*Интернет ресурслар.*